КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 16 июль г.Казань № 587

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, җирле үзидарә органнарының коммерциягә карамаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре белән ведомствоара хезмәттәшлеге регламентын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, җирле үзидарә органнарының коммерциягә карамаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре белән ведомствоара хезмәттәшлеге регламентын расларга.

2. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына коммерциягә карамаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре белән үзара хезмәттәшлекне тәэмин итү максатларында чаралар күрүне;

Татарстан Республикасының Иҗтимагый палатасына:

«Татарстан Республикасының Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган Татарстан Республикасының Иҗтимагый палатасы максатларын һәм бурычларын тормышка ашыру максатларында ведомствоара хезмәттәшлектә катнашучылар белән үзара хезмәттәшлек итүне;

коммерциягә карамаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре эшен координацияләүне;

коммерцияле булмаган оешмаларга ярдәм итү мәсьәләләренә бәйле ведомствоара хезмәттәшлек нәтиҗәләре буенча җәмәгатьчелек тыңлауларын (шул исәптән тиешле муниципаль районнарда һәм шәһәр округларында) оештыруны;

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан тормышка ашырыла торган чаралар турында мәгълүмат урнаштыруны.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин